

ПЕТР ФРАНЦЕВИЧ ЛЕСГАФТ

# ПЕТР ФРАНЦЕВИЧ ЛЕСГАФТ

Дөньяда яшәүнең магнәсе — хезмәттә, үзеңә эшләүдә түгел, ә башкалар өчен эшләүдә... Гел башкалар файдасына гына эшләү — үзенең исме — кеше булганы өчен генә башкалардан хөрмәт күрүгә һәрбер кешенең хаклы икәнен аңлаучы кеше өчен генә мөмкин эш".

Бу сүзләрдә, патша Россиясенең караңгылыгы һәм кысуы эчендә үзенең байрагын төшермичә, бөтен гомере буена бөек идеяләргә хезмәт иткән Петр Францевич Лесгафт тулысынча үзе чагыла. Петр Францевич Россия самодержавие режимының бөтен авырлыгын татыды һәм галим, педагог булу сыйфатында үзендәге барлык чаралардан файдаланып, изү һәм башбаштаклыкка каршы өзлексез көрәш алып барды.

Петр Францевич 1837 елда ювелир семьясендә туды. Петр үсә төшкәч атасы аны аптекага эшкә өйрәнергә бирде, ләкин малайга аптека ошамады һәм ул аннан качып китте. Атасының моңа бик нык ачуы килде һәм ул улыннан кул селтәде. Берничә вакыт уйланып, икеләнеп йөргәннән соң Петр Францевич гимназиянең өлкән классларының берсенә керер өчен үзе әзерләнмәкче булды һәм бу теләген, үзенең абыйсы Александр ярдәмендә тормышка ашырды. Гимназиядә ул яхшы укып барды һәм аны көмеш медаль белән тәмам итте. Гимназияне бетереп чыкканнан соң Петр Францевич медицина - хирургия Академиясенә керде. Ул, Академиядән якын гына урыннан бер кечкенә бүлмә алды да, дәресләр укытып тапкан акчага бер үзе тора башлады; эше очраклы һәм аз булганга күрә, аңа кай вакытларда ачыгырга да туры килгәли иде.

Ул Академиядә дәртләнеп, гадәттән тыш тырышып укыды — бу сыйфатлар аның эшлекле натурасының төп аергычлары иде. Беренче уку елларында ул химия белән бик кызыксынды һәм профессор Зинин карамагындагы химия лабораториясендә күп эшләде. Профессор Зинин аның эшенә бик яхшы бәя бирә иде. Ләкин соңыннан П. Ф. Лесгафт, атаклы профессор Грубер җитәкчелегендә бик нык бирелеп анатомия белән шөгыльләнә башлады һәм 1861 елны академияне бетергәч тә үзен бөтенләй шушы фәнгә генә багышлады. Анатомия кабинеты прозекторы һәм анатомиядән укытучы булып калды.

Венцеслав Леопольдович Грубер үзенең башкалардан аерылып торган сөекле шәкерте — П. Ф. Лесгафтның фәнни яктан җитлегүенә, әлбәттә, тәэсир итте. Профессор Грубер, үзенең милли чыгышы ягыннан немец иде, ул Россиядә 40 елдан артык эшләде, Россия аның өчен икенче ватаны булып әверелде. Зур эрудицияле галим, нык характерлы һәм эштә искиткеч сәләтле Грубер берничә мең рус врачларын тәрбияләп чыгарды. Аның фәнни хезмәтләренең саны 500 гә җитә. Аның җитәкчелеге астында Петербургта яңа Анатомия институты салынды, ул фәнни кабинетлар һәм музей ачучы һәм оештыручы булды. Груберны — бу зур галим, оригиналь кешене кем генә белми? Ул властьләр алдында нык тора, аларга баш ими, полиция белән булган бәрелешләрдә студентларны җаны-тәне белән яклый, ләкин шуның белән бергә, ул үзе укыткан яшьләр алдында да шулай ук башын ими, яшьләрдән төгәллекне, белемне таләп итә һәм бу таләпләре белән фәнгә һәм үз специальностенә җидди карау — үзенә һәм җәмгыятькә карата булган вазыйфаң, бурычың икәнлеген аңлата иде. Петр Францевич та шундый ук чыныгу алган кеше иде — ул үзенең холкы буенча башкаларга бәйсез, үзенең фәнен өзелеп яратучан һәм студентларның укуын әллә нинди көнчелек белән тикшереп торучан кеше иде... Ул көчле һәм юньле иде... Простой һәм җидди иде...“ дип яза аның турында үзенең истәлекләрендә, Шлиссельбург крепостендә 20 ел тоткында утырган атаклы революционерка В. И. Фигнер.

1868 елның көзендә П. Ф. Лесгафт Казан универси-

тетына физиологик анатомия кафедрасына сайланды. Бу кафедрада 30 ел укыткан һәм студентларның зур мәхәббәте һәм ихтирамы белән файдаланган профессор Аристовның эшен дәвам иттерүче булды. Хәзерге көндә дә Казан анатомия институтының аудиториясе Е. Ф. Аристов исемендә йөртелә. Профессор Виноградов, 1869 елның 19 нчы мартында, Петр Францевичның Казан университетында укыткан беренче ел ахрында ук аның турында болай дип яза: „Лесгафт әфәнденең укытучылык эшендәге барлык сәләтлекләре турында факультетта булган мәглүматларга карап аннан көтелгән нәрсәнең барын да ул артыгы белән бирде. Үзенең лекцияләрен профессор Лесгафт сөйләвенең тулылыгы һәм акыллылыгы белән бергә, үз предметын бик яхшы белүгә һәм аңа тирән бирелгәнлеккә хас булган энергия белән укый. Бу сыйфатлары белән бер рәттән анда шулай ук искиткеч эш сөючәнлек бергә кушыла: ул студентларны атнасына 24 сәгать укыта һәм аның өстәвенә якшәмбе көннәрне хирургия анатомиясеннән курс укый. Бу курсның студентлар өчен мәҗбүри булмавына, лекцияләрнең якшәмбе көн укылуына һәм 2—3 сәгать сузылуына карамастан, аудитория һәр вакыт тулы була“.

Бу сокланып язылган характеристика аның факультет коллегасы, профессор тарафыннан бирелгән иде. Менә тагын, лекцияләрен тыңлаучы студентларга Петр Францевичның нинди тәэсир калдыруы турындагы таныклык: „Петр Францевичның үз предметына булган энергияле, саф мәхәббәте студентларга ирексез күчә иде, — дип яза Фингер, — студентлар тыңлаучылар түгел, нак шәкертләр иде. Анатомия залына килеп керү белән студент тышкы дөньяны оныта, аны укытучы тәмам үзенә карата, үзенә бәйли һәм аның җанын үзенә ошатып үзгәртә кебек иде... Аңа беренче якын килү белән үк, анда „кеше“ сизелә һәм матур шәхес белән яхшы укытучы сыйфатлары гүзәл булып бергә кушылудан сокландыргыч бер хис туа иде. Бу хис үзләренең студентлык елларын аның җитәкчелеге астында башлау бәхетенә ирешкән буыннар өчен Лесгафтны үрнәк һәм идеал итеп әверелдерә иде. Үзенең укуын һәм тормышын башлап җибәрүче һәрбер кеше өчен кешеләр нәселенең гүзәл үрнәге булырлык

кеше белән очрашу иң зур бәхет булып санала, чөнки бу очрашу кай вакытларда кешенең киләчәген билгеләгән иң көчле факторларның берсе була. Һәм менә университет бусагасында, укучы яшьләр Петр Францевичта шундый үрнәк очраттылар. Петр Францевич бик сөйкемле иде. Ул анатомия курсын укыта. Моннан да күңелсез нәрсә бар инде? Ә уку сәгате сизелмичә үтә, аудитория шыгрым тулы, студентлар кыймылдамыйча, иң кызыклы доклад тыңлаган кебек бирелеп тыңлыйлар. Петр Францевичның кешене тыңлата алу таланты бар иде: сөйләнә торганның бары да кирәкле, бары да зарур, бер нәрсәне дә төшереп калдырырга ярамый, аларны киләчәк өчен истә нык калдырырга кирәк икәнен тыңлаучылар аңлыйлар иде. Алар профессорның тыңлаучының күңленә медицина белеме фундаменты салуын һәм бу фундаментның ныклыгына, җиддилегенә аның—яки врач, яки фән эшчесе булып эшләячәк тыңлаучының — бәлки бөтен киләчәге шуңа бәйләнгән булу ихтималын сизәләр иде. Петр Францевичны студентларның тирән ихтирамы чолгап алган иде. Препаровочныйда ял вакытларында, өйләрендә бер-берсе белән очрашкан чакларда студентлар аның турында күп сөйләшәләр. Ул беренче курстагылар өчен үзәк фигура, аннан куркалар да, яраталар да иде".

Лесгафт — табигать тарихы мәктәбен узган биолог, ул анатомия курсына бу фәнне (анатомияне) киң магнәдә аңлауны кертә һәм аны, бу дисциплинаны студентлар өчен һәркайчан күңелсез әйбергә әйләндергән тасвирлау методы әйләнәсеннән чыгара иде. Ул күренешләрне тасвирлауны гомуми идеяләр белән бәйли белә, фәннең тормыш белән бәйләнешен конкрет үрнәкләр белән күрсәтә белә иде".

— Сезнең мондый картинаны күргәнегез бармы? Бу — күз алдыгызга китерә алмаслык гүзәл картина,— ди торган иде П. Ф. Лесгафт нинди дә булса берәр үлек тканьнең препаратына күрсәтеп. Үз-үзен оныту дәрәҗәсенә җитеп фән белән мавыккан Петр Францевич, тормыштан бер вакытта да читләшми һәм тирәяктагы тормышны аңлаудан ерак булган, кабинетында утыручы галимнәрдән ул көлә иде.

— Мондый галим урамнан барганда фонарь баганасына килеп бәрелә дә, бу фонарь урынсыз урынга

куелган икән дип уйлый, —ди торган иде Петр Францевич.

Аның лекцияләре тышкы яктан да — сөйләвенең рәвеше ягыннан да бик кызыктыручан иделәр. Аның һәркайчан кайнап торган тормышы, предметын, аудиториясен яратуы аны рухландыра иде; менә шуннан, сөйләгән нәрсәсенә карап тавышының төрлелеге, бай мимикасы килеп чыга: ул я елаган, я көлгән баланың йөз мышцылары үзгәрүен үзе кыланып күрсәтә, я Советның, кеше фикренә һәр вакыт кушылучан „яхшы" членының күзәтүләре турында сөйли һәм боларны теләсә кайсы артист көнләшерлек итеп бик оста кыланып күрсәтә иде.

Препаратларны демонстрацияләгән вакытта Лесгафт студентларга һәр вакыт әйтә торган иде: „Бармагыгыз белән кагылыгыз һәм ышаныгыз". Бу сүзләрдә аның педагогик методының төп юнәлеше — табигать аркылы сизү һәм шуна күрә бөтен гомеренә хәтердә калдыру күренә иде.

Петр Францевич Россиядә хатын-кызларга югары белем бирүне оештыручыларның берсе итеп исәпләнергә тулысынча хаклы. Казанда ук үзенең педагогик эшенең башында ук, ул, чикләүләргә һәм тыюларга карамастан, Анатомия институтында „тынлаучы" хатын-кызлар белән занятиеләр уздыра иде. Вера Фигнерның истәлекләрендә, Петр Францевич тарафыннан тәрбияләнгән һәм Анатомия театрына эшкә тартылган беренче хатын-кыз—ассистентканың образы гәүдәләндерелә. Фигнер аны болай тасвирлый: „Озын буйлы, ирләрнекенә ошаган йөзле ябык кыз, Анатомия театрында зур эш алып бара, 12—14 сагәт эшли иде. Аның Евгени Мужскова фамилиясе, тышкы кыяфәтенә бик туры килә иде; ул хатын-кызлар керә алган бердәнбер медицина уку заведениесенең акушерлык курсларында укый иде. Петр Францевич Мужскованы ассистент итү турында факультет алдында ходатайлык итте. Университетның һәм факультетның Советы мона каршы килмәделәр, ләкин попечитель рөхсәт бирмәде.

Петр Францевич Лесгафтның көчле энергияле, тормышның яңа, яхшырак формаларына омтылучан бәйсез натурасы патша чиновниклары һәм консерватив профессура тарафыннан, әлбәттә, үзенә каршы-

лыклар очрата алмый калмады. Аның Казан университетындагы эше өч елга якын дәвам итте һәм „Лесгафт тарихы" дигән эпизод белән тәмамланды.

Алтмышынчы елларның башындагы либераль реформаларның берсе булып. 1863 елда Казан университетына кертелгән яңа устав, университетка кайбер автономиялек бирде: ректор сайланып куела башлады, университет эшләрен һәм башка эшләрне хәл итә торган коллегия буларак, Советның әһәмияте үсте. Ләкин боларның барсы да учебный округ попечителе тарафыннан юкка чыгарылды. Попечитель булып ул вакытта консерватив карашлы Шестаков тора иде. Яңа уставның принципларын бозган попечительнең политикасы һәм университет Советындагы консерватив профессорлар группасының шулай ук уставны боза торган хәрәкәтләре Лесгафтның бик нык ачуын чыгардылар, һәм ул куркып тормады бу турыда матбугатта язып чыкты. 1871 елның январендә „С. Петербургские Ведомости"дә авторның кулы куелмаган бер мәкалә басылып чыкты, ул Казан университетындагы тәртипләрне тәнкыйтьләгән һәм башлыча „университетны буйсынучан гимназиягә, яки, дөресрәге, сүзсез баш июче чиновниклар канцеляриясенә әверелдерергә маташучы" попечительгә каршы язылган иде.

Моңа кадәр булмаган мондый хәл — университет эшләрен бөтен халык алдында фаш итү — профессорларны, бигрәк тә попечительне, бик тынычсызландырды. Ләкин мәкаләгә кул куелмаган булу сәбәпле Лесгафтка карата кискен чаралар күрергә кыймадылар. Лесгафт үзенең авторлыгын яшерми, һәм студентларга лекцияләрдә бу турыда әйтә иде. Шул ук елның көзендә газетада Лесгафтның икенче мәкаләсе чыкты, бу юлы инде аның тулы имзасы куелган иде. Мәкалә „Казан университетындагы хәлләр" дип аталган иде. Мәкалә түбәндәге сүзләр белән башланып китә: „Һәрбер башбаштаклык күңелне әрнетә, ләкин бу башбаштаклык һәм законсыз эшләрдән яклаучы булмаса,ниләр эшләнгәнен тикшерү түгел, хәтта сине тыңлаучы да булмаса, бер генә чара кала, — ачыктан-ачык әйтеп бирү. Мин университетның Совет члены булуым ягыннан гына миңа кагылган гомуми эшләренә тукталмыйм, чөнки бу күп вакытны алыр

иде, хезмәтемне университеттагы кайбер иптәшләрем уртаклашуына ышанам, мин тик үз кафедрам буенча гына кайбер фактларны китермәкче булам, чөнки бу фактлар университетта чын анатомиянең ни хәлдә яшәгәнен һәм аңа попечитель әфәндегең нинди йогынтысы булуын аңлатып бирә алырлар".

Мәкаләнең азагында Лесгафт университеттагы акча суммаларына хыянәт итүләрне күрсәтә: „Бу фактлар коллегияле учреждениенең членнары арасында могамәләнең начараюына алып баруын бик ачык күрсәтәләр, чөнки бер нәрсә дә кычкырып әйтелми (протоколлар басылмый, каршы килүчеләрне кире кагалар, аерым фикерләрне тыңламыйлар һ. б.), ә начальство законга каршы эшләрне яклап килә. Зур кызганычка каршы, бу нормаль булмаган мөнасәбәтләр университетның кайбер эшлекле членнарын, мәсәлән, профессор Ковалевскийне, Вагнерны, Павлов һ. б. университетны ташлап китәргә мәҗбүр иттеләр; аларның кафедралары буш тора, яки төрле законсыз юллар белән белеме йомшак кешеләргә бирелә, һәм шулай итеп университет торган саен артка чигенә (төшенкелеккә бара)".

Бу мәкалә 23 нче сентябрьдә басылып чыкты, ә октябрьдә патша Александр II нең „Бөек әмере" буенча П. Ф. Лесгафт университеттан чыгарылды; аңа укытучы булу тыелды. Университет Советының 1871 елның 6 нчы ноябрендә булган утырышы протоколында халык мәгарифе министренең профессор Лесгафтка карата бирелгән боерыгының тулы тексты бар: „Казан университетының экстраординар профессоры Лесгафтның начар ниятле эше турында — аның „С. Петербургские Ведомости" дә Казан университеты Советына каршы һәм Сезнең Превосходительствога каршы яла ягу һәм фактларны бозу белән тулган мәкаләсен бастырып чыгуы турындагы минем всеподаннейше (чын күңелдән бирелеп язылган) докладым буенча, — Гасударь император, ошбу октябрьнең 14 нче көнендә, Ливадиядә, Высочайше әмер бирде: Казан университетының экстраординар профессоры, Коллежский Советник Лесгафтны хезмәтеннән прошение бирдермичә чыгарырга һәм киләчәктә укыту эше буенча аны бер урынга да алмаска".

Ректор боерыгын алганнан соң ике сагәт вакыт

үткәч тә Петр Францевич анатомия кабинетын тапшырды һәм хезмәт вазыйфаларын үтәвен туктатуы турында хәбәр итте. Лесгафтның китүе турында Вера Николаевна Фигнер менә ничек сөйли: „Бер көнне иртән без сеңлем белән Анатомия театрына барып, препаровочный бүлмәсенә керсәк, бик гаҗәпләндек: өстәл өстендә үлекләр гәүдәләре дә юк, студентлар да күренми, Лесгафт килмәгән. Менә шунда безгә Лесгафтның профессорлыктан алынып ташлануы һәм киләчәктә кая булса да укыту хокукыннан мәхрум ителүе турында әйттеләр. Ни өчен? Бу хәбәр шундый коточкыч, ышанмаслык иде... Соңыннан студентлар, бигрәк тә Лесгафтны якын күрүчеләр, һәр вакыт туры сүзле, кискен Лесгафтны кайбер профессорларның яратмавы турында, университет яшьләренә зарарлы йогынты ясауда гаепләп аның өстеннән донос язулары турында сөйләделәр... Петр Францевич өчен йөрәк әрнеде. Без аның өенә киттек. Анда бөтен нәрсәнең асты өскә килгән иде. Мебельләре, савыт-сабалары сатыла. Тормышы чын-чыннан җимерелә иде. Петр Францевич хатыны һәм кечкенә улы белән средствосыз һәм киләчәккә перспективасыз калалар иде. Бөтенесе җимерелә, тормышны яңадан, яңа урында, башка обстановкада, яңа шартларда башларга туры килә иде. Мораль югалтулар барыннан да читенрәк булды. Петр Францевич — үзенең табигый сәләтлеге буенча укытучы — аудиториядән, үзе сулаган атмосферадан үзе теләгәнчә киң колачта эшләүдән мәхрум ителә иде. Аның тышкы кыяфәте тыныч, һәр вакыттагы гадәте буенча бераз ирония белән сөйли һәм без аннан бер генә искергән, мондый вакытларда әйтелә торган фразаны да ишетмәдек — ул бик тотнаклы иде. Үзе кичергән хәл турында ул бер сүз дә әйтмәде."

Лесгафтны эштән чыгаруга протест белдереп, җиде профессор — Головкинский, Денилевский, Имшенецкий, Морковников, Якобий, Голубев һәм Левицкий Казан университетын ташлап китүләре турында гариза бирделәр. Берничә башка профессорлар китүчеләргә үзләренең теләктәшлеген рәсми рәвештә белдерделәр: „Фәннең шундый зур хезмәтләр күрсәткән җиде укытучысының университеттан чыгып китүе, университет өчен шул кадәр мөһим югалту булып

тора ки, Совет аларның эштән китүләренә пассив рәвештә генә килешеп кала алмый. Бәлки бу укытучыларга аларның гыйльми эшчәнлегенә теләктәшлек белгертергә һәм университетта калуларын сорарга тиеш" — дип яздылар профессорлар Ковальский, Суботин, Катеьников һәм Шпилевский. Профессор Булич тә үз фикерен әйтеп бирде: „Укыту эшенә зарар китереп, шулай яхшы профессорларның университеттан китүе кызганыч. Совет членнарын шундый мөһим адым ясарга мәҗбүр иткән сәбәпләрнең булуы бик кызганыч" диде.

Лесгафтны эштән алу һәм аңа теләктәшлек күрсәтүче бер группа профессорларның демонстратив рәвештә эштән китүләре студентлар арасында чуалыш китереп чыгарды: протестлар яздылар, демонстрацияләр оештырылды һәм студентлар яңа укытучыны анатомия кафедрасына озак кына җибәрми тордылар — алар Лесгафттан соң кафедрага күтәрелгән яңа укытучыны сызгырып кафедрадан төшерәләр иде. Студентлар арасындагы чуалышлар начальствоны бөтен уку елы буена тынгысызладылар.

Петр Францевич Петербургга китте һәм Хәрби Медицина Академиясенә профессор Грубер янында үзара танышлык белән урнашты — Груберның исме һәм авторитеты кимсетелгән галимгә үзенең яраткан специальностен ташламыйча эшләргә мөмкинлек бирделәр. Лесгафт кебек үк, Грубер дә хатын-кызларга белем бирү эшен бик нык яклаучы иде һәм ул үзенең Анатомия театрына анатомия укырга хатын-кызларны да алган иде. Хәрби Медицина Академиясенең стеналары эчендә хәтта хатын-кызлар түгәрәге дә оештырылды, бу түгәрәккә катнашучылар арасында Россиядә хатын-кызлардан булган беренче врачлар — Суслова һәм Кашеваровалар бар иде. Петр Францевич менә шушы түгәрәк белән җитәкчелек итә башлады. Өч елдан соң, бу түгәрәктә инде йөздән артык кеше санала иде.

Тиздән П. Ф. Лесгафтка хәрби хезмәткәрләр өчен гимнастика күнегүләрен эшләү тапшырылды. Чит илләрдә физик белемнең куелышы белән танышу өчен ул Германиягә, Франция һәм Англиягә җибәрелде. Аннан кайткач Петр Францевич гаскәрләр өчен гимнастика курслары оештырды. Ләкин „ышанычсыз"

Лесгафтны соңыннан гимнастика курсларыннан читләттеләр һәм эшне башка бирәүгә тапшырдылар.

Ләкин физик үсешнең идияләре Петр Францевичны бик кызыктыралар иде — ул аларны тирәнәйтә, биология ягыннан нигезли бара һәм нәтиҗәдә „Лесгафт системасы" исемендәге система килеп чыга. Бу гимнастика системасының бер төре генә түгел, кеше шәхсенең гармонияле үсеше өчен нигез салган яңа таглимат иде. Укымышлы шәхесне, пассив белемнәр түгел, ә бу белемнәр белән файдалана белү, коры күнегүләр түгел, ә бу күнегүләрне үзең дә барлыкка китерү булдыра, дип өйрәтте Лесгафт. Физик упражнениеләр бу күнегүләрне үзеңдә булдыруга ярдәм итәргә тиешләр. Ул бер вакытта да физик белемне акыл белеменнән аермады. Физик белем — конкрет булмаган фикер йөртүне китереп чыгарган физик энергияне бушка, файдасызга тотуны булдырмаска тиеш. Үзенең физик үсеш турындагы таглиматын Лесгафт „Мәктәп яшендәге балаларга физик белем бирү буенча кулланма" дигән капитал хезмәтендә бәян итте. Бу китапта педагогика тарихы өлкәсеннән аеруча кыйммәтле материал булган төпле тарихи очерк бирелгән.

1880 — 1885 еллар Петр Францевич Лесгафтның зур фәнни эш алып бару чоры булып тора. Шул елларда ул „Теоретик анатомия" дигән үзенең капиталь хезмәтенең нигезен салды, анатомия буенча 22, физик үсеш буенча 6 хезмәтен бастырды, аның җитәкчелегендә докторлыкка 21 диссертация язылды. Аның хезмәтләренең күп өлеше чит ил телләренә күчерелде һәм аның исеме Европада нык таралды.

Лесгафт теоретик анатомияне тудыручы булды. Аны аңа кадәр булган галимнәр һәм шул чагындагы галимнәр кулланган коры тасвирлау методы канәгатьләндермәде. Ул, кеше организмының, органнарның формасын һәм функциясен белү өчен биологик анализ кулланып өйрәнде. Аның методы анатомия белән янәшә торган дисциплиналарны — физиологияне, психология, потологик анатомияне, чагыштырма анатомияне, эмбриология, химия һәм физиканы үз эченә ала иде.

Лесгафт таглиматының нигезендә — тышкы шартларның тәэсире астында үз формасын үзгәртүгә

ихтиаж булу организмга хас сыйфат дигән караш ята иде. Органның эшчәнлегенең эзлекле кабатлануы аның формасын билгеле бер юнәлештә камилләштерә. Шулай итеп, форманың үзгәрү проблемасын Лесгафт Ламарк[1] таглиматы рухында аңлатты (ул Ламаркның дәртле иярчене иде). Дарвин тарафыннан ачылган төр ясалышының дөрес закончалыгын Лесгафт төшенә алмады. Бу — Лесгафтның төп хатасы, ул хата аның гыйлми мирасының үз вактында фәнни фикер үсешендә мөһим этап булса да, безнең көннәрдә ул тарих байлыгы булып кына калуына сәбәп булды.

Хәрби Медицина Академиясендә Лесгафт 1878 елда, димәк, Петербургга күчкәннән соң җиде ел үткәч кенә укыта башлый, анда да әле икенче прозектор булып кына. Петербург университеты исә Петр Францевичны табигат факультетында анатомия буенча лекцияләр уку өчен тик 1885 елда гына чакырырга мөмкинлек алды. Аның лекцияләренә башка факультет студентлары да — филологлар, юристлар да йөрделәр; аудитория лекцияләр барганда һәр вакыт тулы була. Начальство аны сөйми. Күренекле галим һәм талантлы лектор булса да, ул приват-доцент исемендә генә йөрде, Советта катнашмады. Практик занятиеләр өчен Лесгафтка кечкенә генә дворник будкасына ошаган, бүлмә бирелгән иде.

Петр Францевич университеттан тыш Рождественский фельдшерлар курсларында һәм өйдә анатомия буенча лекцияләр укыды. Аның кечерәк кенә квартирасында иртәнге 7 сәгаттән тыңлаучылар җыела; күбесенә утырып торырга туры килми, басып тыңлыйлар. Бу өйдәге курсларга эләгүе бик читен, чөнки аларга бер ел диярлек алдан язылалар иде. Петербургның ерак читләреннән җәяүләп егетләр һәм кызлар киләләр — бу дәртле шәкертләрне бернәрсә дә туктата алмый иде, чөнки Петр Францевичның лекцияләрендә, алар, кызыклы итеп укытылган предметтан белем алудан тыш, шулай ук тормышның нигезләрен һәм принципларын өйрәнәләр иде. „Аның лекцияләре кешедә рухани үзгәреш ясый, һәм гомер буена тирән эз калдыра иде" — дип язды аның шә-

---

[1] Жан Ламарк — францияле табигат тикшеренүчесе (1744 — 1829).

кертләреннән берсе. „Ул аудиториянең тормыш сорауларына, аның иң кирәкле интересларына тирән илтифат күрсәтә белә иде, ул үзен аудитория дәрәҗәсенә төшерми, ә аны күтәрә һәм яхшырта иде" — дип яза икенчесе.

Лесгафтның өйдәге тыңлаучылары арасында 90 нчы елларның башында күп миллионлы байлыкның хуҗасы Иннокентий Михайлович Сибиряков та бар иде. Ул Петр Францевичның лекцияләре белән мавыга һәм аның эчкерсез һәм фәнгә бирелгәнлеген күреп, аңа бөтен күңле белән бәйләнгән иде. Бер вакытны шулай, көз көне иртә белән (бу 1893 елда булды) Сибиряков Петр Францевич янына килде дә, аңа үз карамагына 200 мең акча такдим итте — бу акча Петр Францевичка үзенең фәнни эшчәнлегендә хезмәтендәге очракларга бәйле булмас өчен һәм гыйлми учреждение оештыру өчен бирелә иде. Моннан тыш, Сибиряков аның карамагына 150 мең сумлык өен тапшырды. Лесгафт бу такдимне кабул итте һәм дәртләнеп биология лабораториясе оештырырга кереште, аның уставы хөкүмәт тарафыннан соңыннан расланды. Лаборатория өчен чит илләрдән кыйммәтле коллекцияләр, препаратлар һәм җиһазлар сатып алынды. Үзенең шәхси тормышын яхшырту өчен Петр Францевич бу акчаларның бер тиенен дә тотмады; ул, квартирымда бер генә урындык та арттырмадым, дип масаеп сөйли иде.

Шул чакта ук Лесгафт, физик белем алуга ярдәм итү җәмгыятен (ул җәмгыят шул вакытта килеп чыккан иде) үз җитәкчелегенә алды. Моңда ул „кухарка балаларының" хокуклары өчен барлык юллар белән көрәште, аларга җәмгыятнең балалар площадькалары һәм башка учреждениеләре белән файдаланырга мөмкинлек бирде, ул бу эшләре белән буржуаз ата-аналарның бик нык ачуын китерә иде.

Тиздән Петр Францевич физик үсеш курсларын оештыруга тотынды. Бу курсларны ачу зур каршылыкларга очрады, һәм тик 1896 елда гына ул рөхсәт алуга ирешке; курслар „физик белем алуның тәрбияләүче һәм җирле хатын-кызлар курслары" исемендә эшли башладылар. Бу курсларда биологик һәм гуманитар фәннәр—тарих, әдәбият тарихы, философия һәм психология укытыла иде. Петр Францевич-

ның үзеннән тыш (аның лекцияләре укучыларны иң нык тартучы көч иде) курсларда укыту өчен шундый шәп һәм талантлы лекторлар — Максим Ковалевский, Нестор Котляревский, Овсянико-Куликовский кебек кешеләр тартылган иде. Һәр вакыт төгәл, бар эшендә җыйнак Петр Францевич башкалардан да һич тоткарсыз шундый булуны таләп итә иде. Ничектер ул бер вакытны бер хөрмәтле лекторны лекцияләрен калдырганы өчен орыша башлаган. Тегесе аны сүзсез генә тыңлап торган да, Петр Францевич читкә киткәч шундагыларга болай дип әйткән: „бу миңа хәтта ошый да, кечкенә вакыттан бирле мине берәү дә шул кадәр шелтәләгәне юк иде" — дигән.

1897 елда Петр Францевич университеттагы эшен ташлады һәм Рождественский курслардан да бушап, үзен бөтенләе белән биология Лабораториясенә һәм физик белем алуның тәрбияләүче һәм җитәкче хатын-кызлары курсларына багышлады.

Үзенең белеме буенча врач буларак, Петр Францевич практик медицина белән дә шөгыльләнде. „Түләүсез. Миңа бөтен врачлар кире каккач миңа киләләр. Һәм минем ярдәм иткән вакытларым да булгалый", — дия иде көлеп, Петр Францевич В. Фигнер белән булган беседасында. — „Әй беләсезме, мин кемне дәвалый идем. П. Н. Дурново[1] улын. Әйе, бер кеше дә ярдәм итә алмаса, минем арттан киләләр иде. Шуның аркасында, — Петр Францевич хәйләкәр елмаеп куя, — ул барын да миңа тырнак та тидерә алмадылар".

Үзенең врачлык эшләрен Петр Францевич бигрәк тә җәй көне, авылга ялга киткәч, киң җәелдерә иде. Крестьяннәр аны яраталар һәм хәтта аңа зурлап баш ияләр иде. Көннәрнең берендә күрше заводда холера эпидемиясе кабынып китә, Петр Францевич көнен-төнен шул йогышлы ауру эчендә үткәрә, нәтиҗәдә эпидемия кыска гына вакыт эчендә бетерелә. Бу хәл Волга буенда коточкыч холера бунтлары дулаган вакытка туры килгән иде. Ләкин бунт турында монда сүз дә була алмый иде. Авыл халкының Петр Францевичка булган ышанычы бик зур, чик-

---

[1] П. Н. Дурново — Эчке эшләр министре.

сез иде һәм аның һәрбер бойрыгы бер сүзсез үтәлеп бара иде.

Петр Францевичның крестьяннарга күрсәткән ярдәме медицина белән генә чикләнми — ул аларны өйрәтә, тәрбияли, авыр моментларда эшлекле ярдәм күрсәтә. Бер вакытны каршы ярдагы өйне яшен суга да, аңа ут кабына. Петр Францевич шунда ук көймә белән теге якка чыга, янган йорт янәшәсендәге өйнең түбәсенә менә дә аны уттан саклау чараларын күрә. Аның артыннан башкалар да эшкә керешәләр, шулай итеп ут сүндерелә. Патша чиновниклары, Петр Францевичның эшчәнлеген һәм халыкка булган йогынтысын киметә төшү өчен Волга буендагы Лесгафт ял иткән авыл священнигына „үгетләү" юлы белән аңа тәэсир итәргә куштылар. Бу күптән түгел генә духовный семинария бетергән яшь священник: „Мин — семинарист, профессорга нәрсә әйтә алыйм соң!" дип җавап кайтарган. Лесгафтның аруны белмичә һәр вакытта эш өстендә януы аның тирәсендәге кешеләрне шак катыра иде. Петр Францевичның эш көне 15—18 сәгатькә сузыла. Тәүлегенә 8 сәгать йокларга кирәк дип исбат итүчеләргә ул: „Гомрегезнең өчтән бер өлешен йоклап үткәрүдән курыкмыйсызмы? Бу бит тормышның өчтән бер өлеше" — ди торган иде. Нинди дә булса эшне иртәгегә калдыру аның гадәтендә юк иде. Аның яраткан фразалары түбәндәгеләр иде: „Эшсез ятмаска", „үзеңне якадан эләктереп алырга", „прогресска илтмәгән һәрбер нәрсә, регресска илтә", „пар өстәргә"...

Буш вакытларын — бәйрәмнәрдә, каникулларда — ул яшьләргә бирә. Бәйрәм көннәрне, еш кына лекция укуларыннан тыш (бу лекцияләре белән ул начальствоның бик нык ачуын китерә иде), Петр Францевич студентлар һәм мәктәп балалары өчен шәһәр буенча һәм шәһәр тирәсенә еш кына экскурсияләр оештыра иде. Ул, производство предприятиеләренә баруга зур педагогик әһәмият бирә — предприятиеләрдә балалар хезмәтенең обстановкасы һәм һәрбер производство процессының баш фигурасы — кеше, эшче белән турыдан-туры таныша алалар иде.

Петр Францевич балаларны бик ярата һәм аларны теләсә нишләтү һәм җәберләүне күргәндә бик кызгана иде. „Балаларны башбаштаклыктан зурларга

караганда да ныграк сакларга кирәк, чөнки зур кеше үзен үзе яклый ала, ә бала үзен яклый алмый" дия торган иде ул. Бер вакытны шулай, ул гувернанткаsuccessfully балага сугуын күреп, үзенең танышының өеннән чыгып китә язды. „Мин балаларны кыйнаган йортта кала алмыйм" диде ул ачынып һәм агарынып. Башка вакытта мондый эш кабатланмас, дип вәгдә алгач кына, ул тынычланды.

Петр Францевич үзен башкаларга карата бәйсез тота һәм кешегә тәлинкә тота белми иде. Министерстводан укучылар өстеннән эчке күзәтү куярга кушкан боерык алгач, ул, бер вакытта да шпион булганым юк һәм булмам да, дип җавап бирде. Курсларда һәм Лесгафтның квартирасында берничә тапкыр тентүләр булгалады. Бер вакытны курсларның көтепханәсендә берничә тыелган китаплар табылды. Петр Францевичтан библиотека өчен җаваплы кешене һич кичекмәстән күрсәтүен таләп иттеләр. Ул, курсларда булган бар нәрсә өчен тик үзен генә җаваплы итеп санаганын әйтте.

Ничектер бер вакытны, эчке эшләр министре Плеве, Петр Францевичны үз янына чакыртып алып аңа болай диде: „Сезнең курсисткаларыгыз бик күп эшләргә катнашкан булып чыктылар, алар әллә нинди бик даулаучан да". Лесгафт аңа болай дип җавап бирде: „Башкача булуы да мөмкин түгел — алар бит һәр иртәне гимнастика белән шөгыльләнәләр" диде.

Үткән йөзнең ахрында, Петербург студентларының инициативасы буенча, бөтен Россиядә студентларның гомуми забастовкасы кабынып китте, ул забастовкада 25 меңнән артыграк студент катнашты. Хөкүмәт, каты репрессия чаралары кулланып, студентларның оешмаларын тар-мар итте: Петербург һәм Киев студентларының күбесе солдатка җибәрелде. 1902 елның 4 нче мартында Петербургның Казанский мәйданында хөкүмәтнең хәрәкәтләренә каршы протест демонстрациясе уздырылды. Полиция һәм казаклар яшьләрне аяусыз кыйнадылар. Әдипләр һәм профессорлар группасы бу тупас җәберләүгә каршы кайнар протест язды. Бу протестның инициаторы Петр Францевич Лесгафт иде. Шул турыда булган җыелышлар өчен ул үзенең квартирасын

бирде һәм үзе бу җыелышларда якыннан торып катнашты. Ләкин 99 имза гына җыюга ирешелде. Петр Францевич кулга алынган студентларның хәлен җиңеләйтү өчен күп энергия түкте, больницаларда ятучы кыйналганнарның санын белде һәм алар турында кайгыртты. Моны хөкүмәт күрмичә кала алмады, әлбәттә: Петр Францевичны Петербургдан сөрделәр. Ул үз эшеннән ирексез китүе белән бик җәберләнгән булса да, Петербург янындагы Териокода урнашып, лаборатория һәм курслары белән эшлекле җитәкчелек итүен дәвам итте. 1902 елда Плеве, Лесгафтка, Петербургка кайтару шарты итеп, кыска гына вакытка чит илгә җибәрү шартын куйды.

1905 елгы революция көннәрендә Петр Францевич үзенең курсларын Ирекле югары мәктәп итеп үзгәртеп оештырды. Аның тыңлаучыларының күбесе халык мөгаллимнәре иде. Бу вакытта Петр Францевич мәктәп йортын салдырып бетерде. Бу йортның квартираларының берендә эшчеләр депутатларының Советы урнашкан иде; ул Советка урын бирүдән бөтен кеше баш тартты, тик Петр Францевич кына аны үз янына сыендырды.

Лесгафт Ирекле югары мәктәбе каршында эшчеләр өчен кичке курслар ачты һәм үзе аларга лекцияләр укыды.

Реакция чорында хөкүмәт Ирекле югары мәктәпнең яшәвен туктатты. Н. А. Морозовка язган хатында Лесгафт бу турыда болай дип язды: „Һичбер сөйләшүсез, каләмне бер тибрәтү белән Россиягә хәзерге вакытта шундый кирәк булган учреждениене бетерү башбаштаклыгы җанны бик әрнетә".

Петр Францевичта җәмагәт университетын оештыру идеясе туа; ләкин аны тормышка ашырырга туры килми, бу аның үлем алдындагы хыялы булып кына кала. 1909 нчы елда бөер авыруы белән бик нык авырганнан соң ул дәваланырга барган җирендә — Камрада үлә. Аңа иптәшкә барган шәкерте үзенең истәлекләрендә болай дип яза: „Юлда аның хәле начарланганнан начарлана барды, ләкин аның бөтен көче һәм кайгыртулары ничек кенә булса да зур расходлар тотудан саклануга юнәлгән иде, чөнки бу расходларның аның юлына акча биргән Лабораториягә артык йөк булып төшүләре мөмкин иде. Ла-

боратория Советынын, аның юлына 2000 сум акча биргәнен белгәч, ул моны бик күп дип санап чын күңленнән ачуланды!"

Петр Францевичны күмү Петербургда бик күп халык катнашы белән булды. Саубуллашу речьләрен сөйләү властьләр тарафыннан тыелган иде.

***

Лесгафт тарафыннан төзелгән биология лабораториясе яшәвендә һәм эшләвендә дәвам итте. Үләр алдыннан бик күп алда ук ул бөтен милкен һәм капиталын биология лабораториясенә тапшыру турында васиятнамә язган иде. 1910 елда Югары курсларны (ләкин университет түгел) ачарга рөхсәт алынды, ләкин бу курсларны Лесгафт исмендә йөртелмәү шарт итеп куелды. Халык мәгарифе министрлары, башта Шварц, соңыннан Кассо, бу „ышанычсыз" курсларның эшен бик тырышып күзәтеп бардылар. 1918 елда Совет хөкүмәте биология лабораториясен дәүләт учреждениесе итеп таныды. Директор итеп карт шлиссельбуржец Н. А. Морозов билгеләнде; ул әле хәзер дә шул постта тора. Аның инициативасы буенча биология лабораториясе профессор П. Ф. Лесгафт исмендәге гыйлми институтка әверелде. Петр Францевичнең физик үсеш өлкәсендәге таглиматы Ленинградда патша сарайларының берендә урнашкан, П. Ф. Лесгафт исмендәге физик культураның дәүләт институты эшләрендә дәвам итә.

Петр Францевич Лесгафтның сирәк очрый торган натурасы рус культурасы тарихында онтылмаслык эз калдырды. Аның шәхсен характерлаучы ике төп сыйфаты — педагогиканың нигезенә куйган тирән акыллылык һәм мәхәббәт иде. Тормышны һәр яктан белүнең киң гыйлми горизонт белән бергә кушылуы, Петр Францевичны эре җәмагәт эшлеклесе итәләр иде. Петр Францевич кешенең шәхсен бөтен нәрсәдән дә югарырак куйды һәм аның иминлеге, аны ихтирам итү, аның гармонияле һәм тулы үсеше өчен көрәште. Шуның өчен ул безгә — совет халкына кадерле, шуның өчен ул үзе үлеп тә, буыннар хәтерендә яшәвендә дәвам итүче гүзәл кешеләр санына керә...

*Профессор В. Н. Терновский.*